ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИ-
ПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-21, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24 декабрь 2025 ел № 27

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
«Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясендә пиротехника эшләнмәләреннән
(фейерверк аттыру) файдалануны тәртипкә
китерү чаралары турында

2025 елның 20 мартындагы «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1994 елның 21 декабрендәге «Янгын куркынычсызлыгы турында»гы 69-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты

**к а р а р б и р ә:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорга 1-3 класслы куркынычлы пиротехник әйберләр (бенгал утлары һәм шапылдаткычлардан тыш) куллануны тыюны билгеләргә:

- сәнәгать объектлары, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линия) чикләреннән 500 метр ераклыкта;

- торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары чикләреннән 50 метр ераклыкта.

2. Ирекле янгын дружинасы әгъзаларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- янгын чыккан очракта халыкка янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлеше турында мәгълүмат җиткерүне оештырырга;

- янгыннарны һәм анда кешеләрнең һәлак булуын кисәтү буенча чаралар комплексын оештырырга.

3. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 21 декабрендәге «Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә пиротехник әйберләр куллануны тыю турында»гы 26 санлы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы М.Н. Мусин